**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
НУРЛАТСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ
РАЙОН ГЛАВА
ГАЙТАНКИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ГӘЙТӘН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШЛЫГЫ**

423014, РТ, Нурлатский район, с. Гайтанкино, ул.  Садовая, дом 17,
Тел. 8 (84345) 3-98-01

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«15» октябрь 2025 ел № 3

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Гайтән авыл җирлегенең Иске Авыл поселогында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына, «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Гәйтән авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 23 статьясына нигезләнеп, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Гайтән авыл җирлеге башлыгы

КАРАР ИТТЕ:

1. 2025 елның 29 октябрендә 11 сәгать 00 минутка Полевая урамы 10 адресы буенча урнашкан мәчет бинасы янында Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Гайтән авыл җирлегенең Иске Авыл поселогында Полевая урамы 1-59нчы йортлардан үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын уздыруны билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

2026 елда Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Гәйтән авыл җирлегенең Иске Авыл поселогы территориясендә теркәлгән һәм яшәүче балигъ булган һәр кешедән 1000 сум сум күләмендә үзара салым акчасы кертергә һәм алынган акчаны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне  хәл итүгә җибәрергә ризамы:

1) Иске Авыл эчендәге юлларны карап тоту һәм грунт катнаш таш җәеп ремонтлау, шул исәптән төзелеш контроле өчен түләүне дә кертеп сезонлы карап тоту.

«РИЗА» «КАРШЫ»

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга (игълан итәргә) һәм Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында http://nurlat.tatarstan.ru/rus/nurlat_poselenia.htm, бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Иске Авыл торак пунктының мәгълүмат стендларында халык җыены этапларын үткәрү датасына кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча урнаштырырга.

8. Әлеге карар басылып чыккан (халыкка игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Гайтән авыл җирлеге башлыгы Н. В. Авдеева